4 класс МАТЕМАТИКА
1 нче вариант

Эшне башкару өчен күрсәтмә

Математикадан мониторинг эшен башкару өчен 45 минут вакыт бирелә. Эш 2 өлештән тора.

1 нче өлештә 14 бирем (А1—А14). Аларның һәркайсына берсе генә дөрес булган 4 җавап китерелә.

2 нче өлеш 6 биремнән (В1— В6) тора. Биремнәрне текстта китерелгән тәртиптә башкарырга киңәш итәбез.

Мөмкин кадәр күбрәк биремнәрне үтәргә һәм күбрәк баллар җыярга тырышыгыз.

Уңышлар телибез!

1 НЧЕ ӨЛЕШ

А1. 873405 санының унарлыклар разрядында кайсы цифра язылган?
1) 7 2) 0 3) 4 4) 5

А2. Ящик 6 кг алма сыйдырышлы. 63 кг алманы тутырыр өчен ничә ящик кирәк булыр?
1) 11 2) 10 3) 13 4) 15

А3. $450:9-50+54\cdot5$ биремендә соңгы булып нинди гамәл эшләнә?
1) тапкырлау 2) бүлү 3) алу 4) кушу

А4. Чиләктә 14 литр су бар, ә бидонда 8 литрга күбрәк. Чиләк белән бидонда бергә барлыгы ничә литр су булган?
1) 36 2) 20 3) 22 4) 6

А5. 91 һәм 7 саннары суммасын 14 тапкырга киметкәннәр. Дөрес язылган гамәл:
1) 91+7:14 2) 91+7 – 14 3) (91 – 7):14 4) (91+7):14

А6. 1, 5, 10, 16, … саннар эзлеклелегенең чираттагысы булып кайсы сан тора?
1) 23 2) 32 3) 22 4) 26

А7. 716 санын 6 бүлгәндә калдык санны күрсәтегез.
1) 56 2) 4 3) 2 4) 8

А8. Периметры 32 см булган квадратның бер ягы ничә см?
1) 8 см 2) 4 см 3) 128 см 4) 16 см

А9. Кадрия 24 кар бөртеген, ә Ильяс аңа караганда 3 тапкырга кимрәк кискән. Балалар барлыгы бергә ничә кар бөртеген кискән?
1) 8 2) 45 3) 21 4) 32

А10. Әйләнә радиусы 6 дм. Бу әйләнәнең диаметры күпме булыр?

1) 3 дм 2) 12 дм 3) 2 дм 4) 18 дм

А11. 15 кг 30 г - ул:

1) 15003 г 2) 1530 г 3) 15030 г 4) 1503 г

А12. Рәсемдә ничә турыпочмаклык бар?



1) 3 2) 4 3) 5 4) 6

А13. $23 \cdot 7$ һәм $13 \cdot 7$ тапкырчыгышларының аермасын табыгыз.

1) 70 2) 2093 3) 148 4) 161

А14. Поезд 5 сәгать буе 60 км/сәг тизлек белән һәм тагын шул кадәр вакытны 40 км/сәг тизлектә барган. Барлык вакытта ул нинди юл узган?

1) 340 км 2) 600 км 3) 500 км 4) 1000 км

2 НЧЕ ӨЛЕШ

В1 – В6 биремнәренең җавабы бөтен сан булырга тиеш. Бу санны бирем номерының уң ягына язарга кирәк. <u>Үлчәү берәмлекләрен язарга кирәк түгел.</u>

В1. 4 линейкалар җыелмасы һәм 2 бетергечнең бәясе 132 сум, ә 4 линейкалар җыелмасы һәм 5 бетергеч – 150 сум тора. Бер бетергечнең бәясе ничә сум булыр?

В2. Укучылар туры юл буйлата 25 каен агачы утырттылар. Теләсә кайсы ике күрше агач арасындагы ераклык берүк. Әгәр ике кырый каен арасы 600 дм булса, бу ераклыкны табыгыз.

В3. Ягы 8 см га тигез булган квадраттан 16 бертигез турыпочмаклык кискәннәр. Бу турыпочмаклыкларның бер ягы 1 см га тигез булса, икенче ягын табыгыз.

В4. Ике кәрзиндә 90 груша бар. Беренче кәрзиннән икенчесенә 10 грушаны алып салгач, беренчесендә икенчесенә караганда 2 тапкырга кимрәк булып чыккан. Башта беренче кәрзиндә ничә груша булган?

В5. Надиянең 200 открыткасы бар. Барлык открыткаларның яртысы – чәчәкле, чиреге – пейзажлы. Калдыкның яртысы – хайван сурәтләре төшерелгән, ә калганнарында кошлар ясалган. Надиянең кошлар ясалган ничә открыткасы бар?

В6. 0, 2, 3, 5, 8 цифралары белән, 5 кә бүленми торган, ничә икеурынлы сан язып була?